***Балалар җәй көне күбрәк  вакытларын урамда үткәрәләр, дуслары белән бергәләп  уйнап, җырлап  төрле уеннар уйнарга омтылылыр.***

***Аларның ял итү вакытлары тагын да кызыграк үтсен өчен, бер ничә җырлы- биюле уен тәкъдим итәбез.***

## Яулык алыш

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кыз лар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:
Талым, талым, талчыбык,
Уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык,
Бир син миңа бер яулык, дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп
чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бире лә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

## Капкалы

Ике бала «капка» ясап (кулларын өскә күтәреп) басалар. Башка балалар, «Әнисә» көенә (татар халык бию көе) бии-бии, капка аша узалар. Кинәт кенә капка ябыла (ике бала кулларын төшерәләр). Капкага эләгүчегә җәза бирелә (шигырь сөйләргә, мәкаль әйтергә һ. б.).

## Түбәтәй

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр. Җыр ахырында түбәтәй кемдә булып кала, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, шигырь сөйли, әтәч булып кычкыра һ. б.). Уен шулай дәвам итә.
Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик еракта килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатырыйм дигәнсең.
Түп-түп-түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

## Яшерәм яулык

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында – кулъяулык. Ул түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:
Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.
Сүзләрне әйткәндә, бер баланың үч төбенә кулъяулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салын-ганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.

## Хәйләкәр төлке

Барлык балалар түгәрәккә басалар. Түгәрәктән бер читтә – «төлке өне» була.
Түгәрәккә баскан балалар күзләрен йомалар. Шулвакытта тәрбияче түгәрәк буйлап йөри һәм бе р балага кулы белән тиеп үтә. Тәрбияче кайсы балага кулы белән кагылса, шул бала «хәй-ләкәр төлке» була. Шуннан соң тәрбияче балаларга күзләрен ачарга һәм хәйлә кәр төлкене эзләп табарга куша. Моның өчен
балалар барысы бергә: «Хәйләкәр төлке, син кайда?» – дип сорыйлар һәм, хәйләкәр төлке үзен күрсәтмәсме дип, як-якка караналар. Берникадәр паузадан соң тагын бер тапкыр сорап ка-
рыйлар. Өченче тап кыр сораганнан соң, хәйләкәр төлке: «Мин монда!» – дип кычкыра һәм уенда катнашучыларны куа башлый. Уйнаучыларның төрлесе төрле якка йөгерә ләр. Тотылган
балаларны төлке үз оясына алып китә.
Төлке 2–3 баланы тоткач, яңа «төлке» сайлана, һәм уен кабатлана.
Уенга күрсәтмәләр
• Төлке балаларны, «Төлке, син кайда?» дип, өч тапкыр сорагач кына куа башлый.
• Әгәр төлке өченче тапкыр сораганчы ук үзенең төлке икәнен сиздерсә, яңа «төлке» сай лана.
• Тотылган балалар арасыннан «төлке» сайланмый.